**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 11 ноябре №37**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 14 ноябрендәге 65 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

1. 3 статьядагы 1 пунктта 4 абзацта ", шулай ук күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен" сүзләрен өстәргә;
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге башлыгы, Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советы рәисе**

**А.Х.Сәгъдиев**